**Татарстан Республикасы Азнакай район Советы карары**

Азнакай шәһәре №172-25 2018 елның "24" гыйнварыннан

«Хезмәт хакы Бердәм тариф челтәре нигезендә исәпләнелә торган Азнакай муниципаль районы бюджетыннан финанслана торган оешмалар хезмәткәрләренең хезмәт хакын арттыру турында» 2011 елның 30 июнендәге 60-10 номерлы Татарстан Республикасы Азнакай район Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында (2011 елның 10 декабрендәге 82-13 номерлы, 2012 елның 20 декабрендәге 206-29 номерлы, 2013 елның 22 октябрендәге 270-37 номерлы, 2014 елның 29 гыйнварындагы 287-40 номерлы, 2014 елның 29 декабрендәге 340-49 номерлы, 2015 елның 07 декабрендәге 16-3 номерлы, 2016 елның 18 августындагы 58-9 номерлы, 24 декабрендәге 128-20 номерлы карарлар редакциясендә)

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Бердәм тариф челтәре нигезендә хезмәт хакы исәпләнә торган Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт хакын арттыру турында» 2011 елның 14 июнендәге 477 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 29 декабрендәге 1123 номерлы карары нигезендә

Татарстан Республикасы Азнакай район Советы карар итте:

1. «Хезмәт хакы Бердәм тариф челтәре нигезендә исәпләнелә торган Азнакай муниципаль районы бюджетыннан финанслана торган оешмалар хезмәткәрләренең хезмәт хакын арттыру турында» 2011 елның 30 июнендәге 60-10 номерлы Татарстан Республикасы Азнакай район Советы карарына (2011 елның 10 декабрендәге 82-13 номерлы, 2012 елның 20 декабрендәге 206-29 номерлы, 2013 елның 22 октябрендәге 270-37 номерлы, 2014 елның 29 гыйнварындагы 287-40 номерлы, 2014 елның 29 декабрендәге 340-49 номерлы, 2015 елның 07 декабрендәге 16-3 номерлы, 2016 елның 18 августындагы 58-9 номерлы, 24 декабрендәге 128-20 номерлы карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктның беренче абзацында «2015 елның 1 октябреннән» сүзләрен «2018 елның 1 гыйнварыннан» сүзләренә алмаштырырга;

күрсәтелгән карарга 1 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карарны веб-адрес буенча Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru. һәм веб-адрес буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга: http://aznakayevo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Азнакай район Советының Бюджет, финанс, салымнар һәм икътисад буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Рәис М.З.Шәйдуллин

Татарстан Республикасы Азнакай
районы Советы карарына
1 нче кушымта
2018 елның "24" гыйнварындагы
172-25 номерлы

Азнакай муниципаль районы бюджет даирәсе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү буенча Бердәм тариф челтәренең тариф коэффициентлары һәм тариф ставкалары (окладлары)

| Бердәм тариф челтәренә түләү разрядлары | Тариф коэффициентлары | Тарифлы ставкалар (окладлар), сум |
|---|---|---|
| 1 | 1,0 | 2329,0 |
| 2 | 1,047 | 2438,0 |
| 3 | 1,09 | 2539,0 |
| 4 | 1,142 | 2660,0 |
| 5 | 1,268 | 2953,0 |
| 6 | 1,407 | 3277,0 |
| 7 | 1,546 | 3601,0 |
| 8 | 1,699 | 3957,0 |
| 9 | 1,866 | 4346,0 |
| 10 | 2,048 | 4770,0 |
| 11 | 2,241 | 5219,0 |
| 12 | 2,423 | 5643,0 |
| 13 | 2,617 | 6095,0 |
| 14 | 2,813 | 6551,0 |
| 15 | 3,035 | 7069,0 |
| 16 | 3,260 | 7593,0 |
| 17 | 3,511 | 8177,0 |
| 18 | 4,499 | 10478,0 |

Искәрмә: җитәкче урынбасарының тариф ставкасы (оклады) күләме тиешле җитәкченең тариф ставкасыннан (окладыннан) 1-2 разрядка түбәнрәк билгеләнә.